ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ
КОМИТЕТ АГРЫЗСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ул. Гагарина, д.13, г. Агрыз, 422230

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ӘГЕРҖЕ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Гагарин ур.,13, Әгерҗе шәһәре, 422230

Тел.: (85551) 2-22-46; Факс: 2-30-61; E-mail: isp.agryz@tatar.ru; www. agryz.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«12» июль 2025ел № 205

«2025 елда Әгерҗе муниципаль районында балаларның һәм яшьләрнең ялын һәм аларны сәламәтләндерүне оештыру турында» Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитетының 04.02.2025 елның 33 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

2025 елда балалыкны яклау өлкәсендә дәүләт сәясәтен гамәлгә ашыру, балалар һәм яшьләрнең ялын оештыру өчен кирәкле шартлар тудыру, мәктәп һәм студентлар каникуллары чорында аларның мәшгульлеген тәэмин итү максатларында, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. «2025 елда Әгерҗе муниципаль районында балаларның һәм яшьләрнең ялын һәм аларны сәламәтләндерүне оештыру турында» Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитетының 04.02.2025 елның 33 номерлы карарына (алга таба - Карар) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

- Карар белән расланган 2025 елга Әгерҗе муниципаль районында балаларның һәм яшьләрнең ялын оештыру программасының II бүлегенең 3 пунктының аталышын түбәндәге редакциядә бәян итәргә: «Муниципаль һәм дәүләт учреждениеләре хезмәткәрләренең һәм коммерциягә карамаган оешмалар хезмәткәрләренең балалары өчен стационар лагерьдагы сменага җаваплы: «Ровесник» яшүсмерләр клубы МБУ, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Яшьләр үзәге» МБУ һәм «Форпост» ЦМ(С)ФООП МБУ».

2. Әлеге карарны "Интернет" мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында бастырып чыгарырга (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составында Әгерҗе муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга (http://agryz.tatarstan.ru).

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары Р.Н. Бадахшинга йөкләргә.

Җитәкчесе И.Х. Салихов